**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**2021 елның 18 ноябре** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 нче төркем инвалидларыннан, ялгыз картлар (80 яшькә җиткән) һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 2022 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Кәүҗияк т. п. Совет ур. зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

2) Кәүҗияк т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу, урнаштыру);

3) газ 3512 махсуслаштырылган техникасын тоту(йөк үзбушаткычы): дизель ягулык- майлау, запас частьләр сатып алу;

4) Кәүҗияк т. п. Совет урамы буенча зират территориясендә зур агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү).;

5) Кәүҗияк т. п. Совет урамы буенча суүткәргечне алыштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү) (озынлыгы 600 м);

6) Кәүҗияк т. п. бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу (Сабантуй, Яңа ел, 23 февраль, 8 Март);

7) некрологларны район «Сарман»газетасында бастырып чыгару.

3. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов